ЛЕНИНОГОРСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
ЛЕНИНОГОРСК РАЙОН
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 16 феврале** **№8**

Лениногорск муниципаль районының 2017 елгы социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2018 елга бурычлары турында

Лениногорск муниципаль районы башлыгы, Лениногорск шәһәре мэры Р.Г.Хөсәеновның 2017 елда Лениногорск муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2018 елга бурычлар турында хисабын тыңлап фикер алышканнан соң, Лениногорск муниципаль районы Советы хисап чорында муниципаль районның икътисадны һәм социаль өлкәне тотрыклы үстерүгә ирешүгә, районның барлык тормыш-көнкүрешен тәэмин итү системаларының тотрыклы эшләвенә, җирле үзидарәне үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән эзлекле сәясәтне гамәлгә ашырганын билгеләп үтә. Район башлыгы муниципаль районның югары вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, гамәлдәге законнар һәм «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә эш итте.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының район башлыгының халык алдында һәм Совет каршында хисап тотуы турындагы нигезләмәләрен үтәп, Лениногорск муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск муниципаль районы башлыгының, Лениногорск шәһәре мэрының 2017 елда Лениногорск муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2018 елга бурычлар турында хисабын игътибарга алырга.

2.2018 елда төп юнәлешләрне гамәлгә ашыру өчен.

<u>2.1. Планлаштыру һәм икътисадый үсеш өлкәсендә:</u>

- районның 2030 елга кадәрге социаль-икътисадый үсеш стратегиясе нигезендә 2018 елга районның социаль-икътисадый үсеш Фаразының төп күрсәткечләрен үтәүне тәэмин итәргә.

- административ механизмнарны камилләштерү һәм муниципаль район икътисадының өстенлекле тармакларына инвесторларны актив җәлеп итү юлы белән уңайлы инвестиция климатын тәэмин итү эшен Әлмәт агломерациясен гамәлгә ашыру нигезендә дәвам итәргә.

- 2017-2021 елларга Лениногорск районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын үтәүне тәэмин итәргә

2.2. Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә:

- торак тапшыру планнарын һәм социаль өлкә объектларын үтәү буенча эш алып барырга;

- күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау программасын җәмәгатьчелекне җәлеп итеп гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

- торак-коммуналь хуҗалыкны модернизацияләүне дәвам итәргә, инновацион һәм энергия саклаучы технологияләр кертүне дәвам итәргә;

-торак-коммуналь хуҗалык тармагында түләү дисциплинасын ныгыту, коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын күтәрү, югалтуларны киметү һәм түләүләр үсешен булдырмау буенча конкрет чаралар күрү өстендә активрак эшләргә;

- йортлар һәм подъездлар буенча өлкән идарәче компанияләр белән берлектә халык арасында торак фондын карап тоту, саклау, торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр һәм аларны вакытында түләү мәсьәләләре буенча аңлату эшләрен көчәйтергә.

2.3. Авыл хуҗалыгы өлкәсендә:

- җирле халыкны продукциябез белән тәэмин итү һәм башка районнарга һәм төбәкләргә сату максатында җитештерү дәрәҗәсен саклап калырга һәм арттырырга;

- авыл халкының эшлекле активлыгын арттырырга, шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерергә;

- «Яшь фермерларга ярдәм» һәм «Гаилә фермаларын үстерү» программаларын гамәлгә ашыру эшен дәвам итәргә;

- федераль һәм республика максатчан программаларында катнашу аша авыл хуҗалыгы предприятиеләренең матди базасын ныгыту чараларын күрергә;

- авыл хуҗалыгы продукциясен сатуны тәэмин итәргә, авыл хуҗалыгы ярминкәләрен оештыру юлы белән сату мәсьәләләрендә фермерларга ярдәм итәргә;

- авыл җирлегендә хезмәт шартларының җәлеп итүчәнлеген арттыру, хезмәт ресурсларының микъдар составын авыл хуҗалыгын үстерү ихтыяҗларына бәйләү, яшь белгечләрне җәлеп итүнең һәм беркетүнең актуаль проблемаларын хәл итү өчен шартлар тудыру, нәтиҗәдә, районның авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген күтәрү.

2.4. Сәламәтлек саклау өлкәсендә:

- сәламәтлек саклау учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуны дәвам итәргә;

-сәламәтлек саклау учреждениеләрен табиблар кадрлары, урта медицина персоналы белән комплектлау эшен дәвам итәргә;

- медицина ярдәменең сыйфатын һәм һәркем файдалана алырлык булуын арттырырга, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм район халкының профилактик эшчәнлеген үстерү эшен оештыру өчен сәламәтлек саклау ресурсларын кулланырга, халыкны диспансерлаштыруга аерым игътибар бирергә.

2.5. Социаль өлкәдә:

- халыкка социаль хезмәт күрсәтү кырарында иҗтимагый берләшмәләр, коммерциягә карамаган оешмалар белән социаль партнерлыкны үстерү кысаларында системалы, килештерелгән эшне арттыру өстендә эшләргә;

- аз керемле, мохтаҗ категориядәге гражданнарга, ветераннарга, инвалидларга адреслы социаль ярдәм күрсәтүне дәвам итәргә.

2.6. Мәгариф өлкәсендә:

- «Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү стратегиясе» комплекслы дәүләт максатчан программасының төп юнәлешләрен гамәлгә ашыруны дәвам итәргә.

2.7. Яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендә:

- торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләр өчен республика программаларын гамәлгә ашыруны дәвам итәргә;

- район һәм республика ярышларында катнашу аша физик культура һәм спорт өлкәсендә яшь гражданнарның инициативасын хупларга;

- район һәм шәһәр халкын физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү эшен башкарырга, күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын яхшыртырга.

2.8. Мәдәният өлкәсендә:

- милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлекләр территорияләрендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

2.9. Законлылык һәм хокук тәртибе өлкәсендә:

- җәмәгать урыннарында законлылыкны һәм хокук тәртибен алга таба ныгытуны, җинаятьчелеккә каршы көрәш өлкәсендә оператив хәлне тотрыкландыруны тәэмин итәргә, балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалауга аерым игътибар итәргә;

- эчке эшләр органнарының оператив-хезмәт эшчәнлеге һәм дәүләт органнары, иҗтимагый берләшмәләр, хезмәт коллективлары һәм халык белән үзара хезмәттәшлеген дәвам итәргә;

- ирекле халык дружиналары эшен активлаштырырга;

- террорчылыкка һәм коррупциягә каршы көрәш чараларын үтәү буенча эшне көчәйтергә.

3. Лениногорск муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә предприятиеләрдән, оешмалардан, төрле милек рәвешләрендәге учреждениеләрдән район бюджетына һәм бюджеттан тыш фондларга салым түләүләренең һәм җыемнарның үз вакытында керүен тәэмин итү чараларын күрергә.

4. Лениногорск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль казна учреждениесе:

-әлеге ресурсларның югары керемлелеген тәэмин итеп, җирдән, муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;

-Лениногорск муниципаль районы территориясендә хуҗасыз күчемсез мөлкәткә муниципаль милекне исәпкә алу һәм сатып алу эшен дәвам итәргә.

5. Лениногорск муниципаль районының «Контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесенә бюджет законнары таләпләре нигезендә бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыруны тикшереп торуны тәэмин итәргә.

6.Лениногорск муниципаль районы Советы Аппаратына Лениногорск муниципаль районы Советының 29 сессиясендә һәм район һәм шәһәр халкы белән очрашуларда әйтелгән тәнкыйть искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрне гомумиләштерергә.

7.Лениногорск муниципаль районы башкарма комитетына 2018 елның 01 апреленә кадәр тәкъдимнәр һәм искәрмәләр үтәү буенча чаралар планын эшләүне һәм раслауны йөкләргә.

8.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгару http://leninogorsk.tatarstan.ru.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лениногорск муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комиссияләренә (Г.Р. Мәүлетова), экология һәм табигатьтән файдалану (И.И. Мишин), социаль мәсьәләләр, мәгариф, мәдәният һәм яшьләр сәясәте буенча (Г.Р. Гаделшина) йөкләргә.

Лениногорск муниципаль районы
башлыгы,
Совет рәисе Р.Г. Хөсәенов